СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 8-29 от «19» 04 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге «Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» № 8-9 карарына үзгәрешләр кертү хакында (26.04.2023 ел, № 10-21, 27.12.2023 ел, №5-26 карарлардагы үзгәрешләр белән)

Мамадыш районы прокурорының 2024 елның 30 гыйнварындагы 02-08-02 номерлы протесты, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге «Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» № 8-9 карарына (26.04.2023 ел, № 10-21, 27.12.2023 ел, №5-26 карарлардагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 12 ноябрендәге 8-9 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карары белән расланган муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлегенең 2 пункты (26.04.2023 ел, № 10-21, 27.12.2023 ел, №5-26 карарлардагы үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Район башлыгы урынбасары Р.Р. Сәмигуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе

А.П.Иванов

000029